ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 110 нче йорт, Макыл авылы,
422582

Тел.: (84379) 34-4-74, факс: (84379) 34-4-95.

12.12.2025 № 03

На № __________ от __________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Исаево торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Җәмәгать хакимияте бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Исаево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 20 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы: - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә буенча 2025 елның 12 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 6 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 6 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 6 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Исаево торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. «Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Исаево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Исаево торак пунктында 2026 елда 20 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы: - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле

әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә буенча карарны таныырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Исаево торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: П.Е. Карпухин